ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
10.01.2024

**К А Р А Р**
№ 2

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 23 маендагы 509 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 23 маендагы 509 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга аукцион үткәрү комиссиясе составына (6 нчы кушымта) (12.05.2023 № 580, 13.07.2023 № 917, 12.10.2023 № 1529 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан комиссия рәисе урынбасары Нигъмәтуллина Айгөл Рәшит кызын - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгын чыгарырга;

Адиярова Ләйсән Хәйдәр кызын, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгечен, комиссия рәисе урынбасары итеп билгеләп куярга;

Комиссия составына Маликова Гүзәл Фәнис кызын - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгечен кертергә һәм комиссия секретаре итеп билгеләп куярга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы сайтына http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин